| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына һәм резерв составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын оешкан төстә һәм үз вакытында хәрби хезмәткә чакыруны тәэмин итү максатларында, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы ФЗ-53 номерлы Федераль законның 26 һәм 27 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» 2016 елның 25 мартындагы ПУ-282 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 июнендә ПУ-538 номерлы, 2016 елның 29 сентябрендәге ПУ-884 номерлы, 2016 елның 20 декабрендәге ПУ-1151 номерлы, 2017 елның 31 мартындагы ПУ-259 номерлы, 2018 елның 24 июнендәге ПУ-537 номерлы, 2017 елның 30 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге ПУ-1177 номерлы, 2018 елның 29 мартындагы ПУ-272 номерлы, 2018 елның 23 июнендәге ПУ-459 номерлы һәм 2018 елның 25 сентябрендәге ПУ-688 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына һәм резерв составына (алга таба – хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составыннан чыгарырга:

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш һәм Яңа Савиново районнары буенча И.Б. Шихбабаевны;

Әгерҗе муниципаль районы буенча Ф.И. Гәрәевны;

Балтач муниципаль районы буенча С.Ф. Ильясованы, А.А. Шакированы;

Бөгелмә муниципаль районы буенча С.А. Бондаренконы;

Нурлат муниципаль районы буенча Н.Х. Сафиуллинны, Л.Н. Мәннаповны;